ГЛАВА БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Октября, д.1Б,
с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Октябрь урамы, 1Б йорт,
Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 6-23-33, факс:6-25-28, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 26** **11 ноябрь 2020 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Бәйрәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

К А Р А Р И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә торак пунктында теркәлгән һәм Абдуллин, Авангард, Вахитов, Кооперация, Мингазов урамнары буенча сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2020 елның 21 ноябрендә 10.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә торак пунктында теркәлгән һәм Октябрь, Пушкин, Сельхозтехника урамы, Татарстан урамнары буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның 22 ноябрендә 09.00 сәгатькә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә торак пунктында теркәлгән һәм Тукай, Ютазы, 1 Май, 8 Март урамнары буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2020 елның 23 ноябрендә 15.00 сәгатькә билгеләргә.

4. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитеты;

- гражданнар җыенының беренче этабын үткәрү вакыты-2020 елның 21 ноябрендә 10.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар җыенының икенче этабын үткәрү вакыты-2020 елның 22 ноябрендә 09.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- гражданнар җыенының өченче этабын үткәрү вакыты-2020 елның 23 ноябрендә 15.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны-Бәйрәкә авылы, Октябрь урамы, 1А йорт, мәдәният йорты;

5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2020 елның 20 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын түбәндәге адрес буенча тәэмин итәргә: Бәйрәкә авылы, Октябрь урамы, 1Б;

- сайлау хокукына ия булган Бәйрәкә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Бәйрәкә торак пунктына халыкка массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итү.

6. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә 2021 елда, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган граждannан 500 (биш йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидлар өчен түләү суммасын 250 сум күләмендә киметеп, үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Бәйрәкә торак пунктында балалар уен мәйданчыгын төзекләндерү (коймалар алу һәм урнаштыру);

- Бәйрәкә торак пунктында административ бина территориясен төзекләндерү (коймалар алу һәм урнаштыру);

- Бәйрәкә авылында чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу);

- Бәйрәкә торак пунктында Абдуллин урамы, Кооперация урамы зираты территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Бәйрәкә торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

- коры агачларны, куакларны кисү; Бәйрәкә торак пункты территориясен җыештыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге

адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык А.О.Әхмәтшина